ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУЛЬБАЕВО-МАРАСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Колбай-Мораса ав. КАРАР

«13» август 2021 ел № 17

Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 23 июнендәге 12 номерлы «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү һәм эшкуарлык эшчәнлеген алып бару өчен кече һәм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан уңайлы икътисадый мохит булдыру максатларында, Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 23 июнендәге 12 номерлы карары белән расланган «2021-2024 елларга Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Колбай-Мораса авыл җирлегендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү» турында муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Программа паспортында «Нурлат муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программасы. Кредит акчалары һәм эшкуарларның үз акчалары. Җирле бюджет чараларын финанслау» сүзләрен түбәндәге сүзләргә алмаштырырга:

«Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбеннән 4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сум)

| Ел | Җирле бюджет чаралары |
|---|---|
| 2021 | 1 |
| 2022 | 1 |
| 2023 | 1 |
| 2024 | 1 |
| БАРЛЫГЫ | 4 |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5нче бүлек белән тулыландырырга:

5. Программаны финанслау:

Кече һәм урта эшкуарлык субъектларына методик, консультация-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук җирле бюджет акчалары исәбеннән финанс, мәгълүмати һәм

башка төр ярдәм алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатында түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сум)

| Чараның исеме | Чаралар күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1 |

1.3. Кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары өчен методик ярдәмлекләр, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Нурлат МР ның Колбай-Мораса авыл җирлеге башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга http://nurlat.tatarstan.ru/ һәм җирлек территориясендә мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ә. Насыйбуллин